ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
УРЫССУ ШӘҺӘР ТИБЫНДАГЫ ПОСЕЛОГЫ СОВЕТЫ

КАРАР № 4

Урыссу ш. т.п. 28-01 20 22 ел

**Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының 23.12.2019 ел, № 23 Урыссу шәһәр тибындагы поселогы Советы карары белән кабул ителгән Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Урыссу шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге территориясендә Төзекләндерү чисталыкны һәм тәртипне үтәү кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Ветеринария турында» Россия Федерациясе Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2021 елның 6 декабрендәге 397-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Ютазы муниципаль районының Урыссу шәһәр тибындагы поселогы Советы карары белән кабул ителгән Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Урыссу шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Урыссу шәһәр тибындагы поселогы Советының норматив хокукый актларын Россия Федерациясе закончалыгына туры китерү максатыннан, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Урыссу шәһәр тибындагы поселогы Советы карар кабул итә:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Урыссу шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге территориясендә Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Урыссу шәһәр тибындагы поселогы Советы карары белән кабул ителгән Төзекләндерү, чисталык һәм тәртип саклау кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 20.1 пунктындагы 25 абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«а) хайваннар авыруларын кисәтүне һәм терлекчелек продукциясенең ветеринария-санитария ягыннан куркынычсызлыгын тәэмин итә торган хуҗалык һәм ветеринария чараларын гамәлгә ашырырга, әйләнә-тирә мохитне терлекчелек калдыклары белән пычратуга юл куймаска, шулай ук ел саен яңадан теркәлү чорында мәҗбүри дәвалау-профилактика чаралары үткәрергә;».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Урыссу шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге территориясендә махсус мәгълүмат стендларында игълан итәргә, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасының Ютазы муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасының Бердәм Дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнарының «Рәсми Татарстан» бердәм Порталы составында

«Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://jutaza.tatarstan.ru/ адресы буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан вакыттан үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Ютазы муниципаль районының Урыссу шәһәр тибындагы поселогы Советының кеше хокуклары, законлылык һәм хокук тәртибе комиссиясенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы
Урыссу шәһәр тибындагы поселогы
Советы Рәисе -
Татарстан Республикасы Ютазы
муниципаль районы Урыссу шәһәр
тибындагы поселогы Башлыгы А. Ә. Шәфигуллин